КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 28 август г.Казань № 722

Предметы Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар сату, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү булган котрактлар өчен банклар хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларга банк хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру турында» 2014 елның 20 сентябрендәге 963 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Предметы Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар сату, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү булган котрактлар өчен банклар хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

контрактның беренче (максималь) бәясе, бердәнбер сатучы (подрядчы, үтәүче) белән төзелә торган контракт бәясе кимендә 1 млрд. сум тәшкил итсә, контрактны үтәү кысаларында банк тарафыннан исәпләүләр мониторингын үткәрүдән гыйбарәт булган контрактка банк хезмәте күрсәтүгә мөнәсәбәттә;

контрактның беренче (максималь) бәясе, бердәнбер сатучы (подрядчы, үтәүче) белән төзелә торган контракт бәясе кимендә 5 млрд. сум тәшкил итсә, хезмәт күрсәтә торган контрактны үтәү кысаларында гамәлгә ашырыла торган банк тарафыннан исәпләүләр мониторингын үткәрүгә өстәмә рәвештә банка тарафыннан бүтән хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган кабул ителә торган товарлар, эшләр (аларның нәтиҗәләре), хезмәт күрсәтүләрнең контракт шартларына туры килүен тәэмин итү мөмкинлеген бирә торган контрактка банк хезмәте күрсәтүгә (киңәйтелгән банк хезмәте күрсәтү) мөнәсәбәттә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин